**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О предоставлении грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии на 2018 год

В целях оказания государственной поддержки наиболее значимым творческим проектам ведущих коллективов в области театрального, музыкального, хореографического искусства и кинематографии, в соответствии со статьей $28^2$ Закона Республики Татарстан от 3 июля 1998 года № 1705 «О культуре» и Указом Президента Республики Татарстан от 2 апреля 2007 года № УП-168 «Об учреждении грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии» **постановляю:**

1. Определить получателями грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии на 2018 год:

Татарский академический государственный театр оперы и балета имени Мусы Джалиля;

Татарский государственный Академический театр имени Галиасгара Камала;

Казанский академический русский Большой драматический театр имени В.И. Качалова;

Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан;

Татарскую государственную филармонию имени Габдуллы Тукая;

Государственный симфонический оркестр Республики Татарстан;

Государственное бюджетное учреждение культуры Республики Татарстан «Татаркино»;

Государственный фольклорный ансамбль кряшен «Бермянчек».

2. Установить общий размер средств на выплату грантов Президента Республики Татарстан в области культуры, искусства и кинематографии на 2018 год в сумме 273 904,6 тыс. рублей.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан установить конкретный размер гранта, предоставляемого каждому получателю, указанному в пункте 1 настоящего Указа.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
09 февраля 2018 года
№ УП-155

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2018 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында**

Театр, музыка, хореография сәнгате һәм кинематография өлкәсендә әйдәп баручы коллективларның аеруча әһәмиятле иҗади проектларына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының $28^2$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 2 апрелендәге ПУ-168 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2018 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын алучылар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры;

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;

В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры;

Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле;

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе;

Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры;

Татарстан Республикасы «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Бөрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле.

2. 2018 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын түләүгә акчаның гомуми күләмен 273 904,6 мең сум итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән грант алучыларның һәрберсенә бирелә торган грантның төгәл күләмен билгеләргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 09 февраль
№ ПУ-155